


ISSN 0868-4545

Г.Тукайның тууына 115 ел тулуга багышлана

Чәчәкләр китерик Тукайга

Яз. Назлы кояш. Апрель. Тукай.

«Чәчәкләр китерегез Тукайга», – дип язган бер мәшһүр шагыйребезнең мондый шигъри юллары бар:

Әйләнәңдә – гөлләр...
Сүзен, гүя,
Шулар аша әйтә күңелләр:
– Туган көнең белән! – дигән сыман
Елмаялар кебек бу гөлләр...

Апрель. Шагыйрьнең туган көне. Тукай һәйкәлләре янында Шигырь бәйрәмнәре тантана итә...

Чәчәкләр китерик Тукайга!



© "Салават күпере", 2001 ел

Габдулла Тукай

Туган тел



И туган тел, и матур тел, әткәм, әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Tuğan tel

İ tuğan tel, i matur tel, ətkəm-ənkəmneŋ tele!
Donyada küp nərsə beldem sin tuğan tel arqılı.
Iŋ elek bu tel belən ənkəm bişektə koyləgən,
Annarı tonnər buyı əbkəm xikəyət soyləgən.
İ tuğan tel! Hərwaqıtta yərdəmeŋ berlən sineŋ,
Keçkenədən aŋlaşılğan şatlıgım, qayğım minem.
İ tuğan tel! Sində bulğan iŋ elek qıylğan doğam:
Jarlıqağıl, dip, üzem həm ətkəm-ənkəmne, Xodam!

Gabdulla Tuqay

Рәссам Светлана ПРИВИНА





Бәхет

Бер шәһәрнең читендә генә өч агай-эне торалар иде. Боларның, нинди генә эшкә тотынсалар да, ни сәбәптәндер эшләре уңга китми иде.

Бу агай-энеләр эшләре уңмавында үз-үзләрен гаепләргә уйлап та карамыйча, һаман Бәхет юклыгыннан гына күрәләр иде.

Бер заман, ничектер, Бәхет, күзгә күренмичә генә, боларга кунакка килде дә, бу өч агай-энегә, нинди генә эш башласалар да, ярдәм итәргә сүз бирде.

Бу вакытта өч агай-ененең берсе сәүдәгәрлеккә тотынган иде. Дәрхаль[1] Бәхетнең ярдәме илә ни сатса – аннан файда, ни алса – аннан табыш итеп, берничә көндә малы вә хәзинәсенең хисабы булмаган бер зур бай булып китте.

Шул ук Бәхет килгән заманда икенче кардәше мәхкәмәдә[2] кятиб (писарь) иде. Бу да Бәхет аркасында хакимлек[3] дәрәҗәсенә күтәрелде; медальләр бирелде.

Сез инде өченчесенә дә Бәхет ярдәм иттеме, диерсез.

Ник итмәсен, итте: өченче кардәш чебен тота иде. Хәзер, Бәхетнең булышлыгы илә, кулын селтәгән саен чебен тота; һичбер селтәгәне бушка китми.

Бәхет кунакка гына килде, дигән идек бит. Дөрес, Бәхет озакламады, китте.

Ике карендәш зур бай вә дәүләтле булдылар. Өченчесе, һаман явыз Бәхетне яманлап, авылдан авылга, сукрана-сукрана, капчык тотып теләнергә китте.



Укучы! Ушбу хикәядә кем гаепле икәнен үзең хаким булып табып хөкем ит.

---

[1]Дәрхаль – шунда ук.
[2]Мәхкәмә – суд.
[3]Хакимлек – судьялык.

Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА





Ләбиб Лерон

Әкиятче малай

Рәссам Фәрит Муллахмәт

Шалтмылтфильм

Әкиятләр укый торгач,
Тәки шомардым, малай:
Ошбу әкиятне үзем
Уйлап чыгардым, малай.

Борын-борын заманнарда
Түгел, бүген заманда
Яшәгән, ди, Кәҗә, Сарык...
Яшиләр, ди, һаман да.




Сарык бик акыллы икән,
Кәҗә аңгыра икән.
Сарык ак сакаллы икән
Кәҗә саңгырау икән.



Берчак урманда йөргәндә
Аю башы тапканнар.
Аю башы: «Сәлам!» дигәч,
Болар куркып чапканнар...



Бераз чапкач, хәл-тын алгач,
Сарык: «Ми-ки-ки!» – дигән.
Кәҗә мескен ишетмәгәч:
– Ул баш синеке! – дигән...



Шуның белән шул: Кырлайга
Болар кайтып киткәннәр.
Вилсәпидләре ватылып,
Көчкә кайтып җиткәннәр...



Тагын борын заманнарда,
Авыз-колак чакларда.
Яшәгән Былтыр, Шүрәле
Сезнең-безнең якларда.



Шүрәле урманчы икән,
Былтыр – чүкеч остасы.
Бер мәлне болар урманда
Очрашканнар, кыскасы.



Бер ботакның булган икән
Нечкә генә ярыгы...
– Кети-кети уйныйк! – дигән
Шулчак урман сарыгы.



Былтыр-оста шүрләп калган,
Дер-дер килгән, кыскасы.
– Гафу ит, Шүрәле абзый, –
Дигән чүкеч остасы.



Ярыкка үз бармакларын
Былтыр кыстырган шулчак.
«Шүрәле быел кысты!» – дип
Былтыр кычкырган шулчак.




Менә шул... Әкиятемне
Тагын укып алыгыз.
Тукай абый язган белән
Аермасын табыгыз.



Айзатка 3 яшь 6 ай,
Айназга 2 яшь 2 ай.

1996 ел.



Айзат белән Айназ мәзәкләре

– Әни, минем чалбарым сөйләшә белә бит.
– Ничек сөйләшә, улым.
– Тишеләм бит инде, тишеләм бит инде, дип әйтә, – ди.

* * *

Су буеннан кайтып киләләр.
– Нишләп, футболкаң юешләнгән, Айназ?
– Ул суда ята иде.
– Ә син үзең кайда идең?
– Футболка эчендә.

* * *

Айназның «р» авазы чыкмый.
– Улым, светофор дип әйт әле?
– Светофо.
– Рубероид дип әйт.
– Аны әйтергә авызым авырта.

Ошбу мәзәкләрне Айзат белән Айназның әнисе ***Илсөяр Минсалих кызы Кәбирова*** *җибәрде. (Аксубай, Яңа Дума авылы.)*

Тукай

Горурланып Тукай белән:
«Безнең Тукай!» – диябез.
Аңардан үрнәк алабыз,
Туган телне сөябез.
«Шүрәле»не, «Су анасы»н
Белми икән кем генә...
Төннәрен сорасагыз да
Яттан сөйлимен менә.
«Яхуд яңа Кисекбаш»ны
Кабат укыйсым килә:
«Тәгәрәп юл уртасыннан
таш килә,
Таш түгел лә – бер киселгән
баш килә...»

Ромашка

Ромашкага карап, уйга калдым –
Күңелем әллә нигә ярсына.
Аллы-гөлле чәчәк тугаенда
Сөендерә барсы-барсы да.
Әкрен генә җилдә тирбәлешеп,
Ромашкалар нидер сөйләшә.
Кояш нурларына кунып йөргән
Күбәләкләр белән серләшә.

Айгөл Хантимерова.
Актаныш, Зөбәер авылы.



Мөдәррис Каюмов, 3 сыйныф.
Түбән Кама районы, Эшчеләр бистәсе.

Кадерле дускай!


Без яшь рәссамнар өчен **«2001 нче елның иң яхшы рәсеме»** дигән бәйге игълан иткән идек. Синнән иң яхшы, иң матур рәсемнәр көтеп калабыз. **Уңышлар сиңа!**




Сөембикә Савельева, 7 яшь. Казан.



Алсу Гыйниятуллина, 11 яшь.
Казан.



Ардуан Нуриев, 10 яшь. Казан.



Илдар Хаҗиев, 9 яшь.
Саба районы.

Сабый Габдулла, ятим Апуш. Дөньяның ачысын-төчесен татып үсәр бу моңлы бала, «Габдулла Тукай» дигән олуг шагыйрь булыр, халкыбыз күңелендә мәңгегә урын алыр. Аның әсәрләрен олысы да, кечесе дә яратып укыр...



Х. Казаков рәсеме.



Кушлавыч авылындагы Тукай туган йорт.


Сабыйга

Һич сине куркытмасыннар шүрәле,
жен һәм убыр –
Барчасы юк сүз,
аларның булганы юктыр гомер.
Жен-фәлән дип сөйләшүләр
искеләрдән калган ул,
Сөйләве яхшы, күңелле,
шагыйранә ялган ул.
Һич өрәк, албасты булган сахралар,
кырлар да юк,
Шүрәле асрап ята торган
кара урман да юк.
Син әле үс һәм укы күп,
шунда аңларсың барын,
Мәгърифәт нуры ачар
күп нәрсәләрнең ялганын.



Л. Фәттахов рәсеме.

Илсөяр Иксанова



Ариэльнең Тукай әкиятендә сәяхәте

– Ариэль, зинһар өчен дим, бу билгесез мәгарәгә кермә, – дип ялынды Себастьян.


– Белмим шул. Ә беләсем килә! – диде дә мәгарәнең тар ишегендә юк та булды Ариэль. Себастьянга су кызы артыннан иярүдән башка чара калмады.

Мәгарәнең тар юлларыннан озак, бик озак йөзделәр алар. Үзсүзле Ариэль Себастьянны тыңламавына үкенә дә башлаган иде инде. Шулвакыт каршыда якты су яланы пәйда булды. Ялан уртасында чәчләрен тарап утырган хатынның алтын тарагы бөтен тирә-юньгә яктылык чәчеп ялтырый иде.

Кем бу? Нинди ят җиргә килеп чыкты соң Ариэль? Сүүсемнәр артына яшеренеп, таныш түгел бу хатынга су кызы бик озак карап торды. Әлегә ул җир асты сулары юлыннан үзенең Кырлай күленә килеп чыгуын да, каршысындагы бу хатынның кайчандыр шушы юллардан килеп, әлеге күлдә яшәп калган Су анасы икәнлеген дә белми. Шулай да Алтын тарак иясенең үзенә һәм туганнарына беркадәр охшаш булуын абайларга өлгергән иде инде.

Ә сез алар арасында нинди охшашлык һәм аермалар күрәсез? Кем соң ул Ариэль? Алтын тарак иясе кем? Аның турында кайсы язучы нинди әсәр язганын беләсезме?








– Әйдә, китик моннан тизрәк, – диде Себастьян.
– Юк, – дип каршы төште Ариэль. – Мин бу түтәй белән танышмыйча китмим әле.

Аннан:
– Кара әле, кара, син дә монда үзеңнең туганыңны табарсың төсле, – дип Себастьянга шаккатып карап торган кыслага ымлады.



Диңгездә гомер кичергән Ариэль өчен бу тирәлек тә ят иде. Ни өчен? Диңгез белән күлнең нинди аермалары бар?

Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА

Былтырның хисабы

(Тукайдан түгел)

Былтыр Сабадан 7 яшьлек Муса Заһидуллин моряк биюен өйрәнде. Ә татар халык биюен ул 5 яшеннән үк бии. Шәп тыпырдый да соң! Хәзер аны бер концерттан да калдырмыйлар.

Былтыр өлкәннәрнең дә, балаларның да яраткан җырчылары Зәйнәп Фәрхетдинова белән Зөфәр Билалов уллары Булатка иптәшкә бер энекәш алып кайттылар. «Ходай кушса, бер сеңлекәш алып кайтырга да каршы түгел мин», – ди Зәйнәп апагыз.



Былтыр Арча районы Сеҗе авылында яшәүче тугыз яшьлек Шәүкәт Заһидуллин Гает көнне ике саваплы эш эшләде. Беренчедән, иртән бик матур түбәтәй киеп, авыл мәчетенә барды ул. Икенчедән, мәчеткә килгән авылдышларының һәркайсына бүләк таратты. Бу бүләк «Намаз уку тәртибе» дигән бик кирәкле китап иде.

Былтыр Казанда яшәүче Тимерханга 1 яшь тулды. Бүләкләр күп булды. Хикмәти хода, нәкъ шул көнне «Салават күпере» журналы да килде. Ә анда мунчада юынып утырган Тимерханның сурәте басылган иде. «Мин бит бу!» дигән бәйгегә җибәрелгән бу фоторәсемгә бик матур шигырь дә язганнар:

– Мунча – бик шәп! Ай-һай эссе! –
Өстик мәллә пар тагы...
– Тимерхан, дим, сиңа әйтәм,
Ышкып алчы арканы.

Тимерхан бу бүләккә аеруча сөенде.

Былтыр Казандагы 16 нчы татар-инглиз гимназиясенең III A сыйныфы укучылары Тукай-Кырлайга бардылар. Шагыйрьнең музеен карадылар, Шүрәле урманнарын күрделәр, бәләкәй Апуш эзләреннән йөрделәр. Шушы сәфәрдән соң алар Тукайның әкиятләрен һәм шигырьләрен тагын да ныграк ярата башладылар.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ.



Былтыр җәй Марс Минаһетдинов белән Ардуан Нуриев Арча районы Сикертән авылында кунакта булдылар. Бергәләп Кесмәстә коендылар, балык каптырдылар. Иң зур балыкны кем тотты дисезме? «Балыкның иң зурысы ычкынды,»– диләр малайлар.

Конкурс!
Мин бит бу?!





– Матай-шатайда йөрдем
Рәхәтләнеп бүген.
Тик шунысы кызганыч –
Үземнеке түгел.

(Казан)



– Самавыр янда, чынаяк кулда –
Сезләргә карап, чәй эчкән мәлем.
Күп сүз сөйләшмим, әйтәм тик бары:
Күз тидермәгез, яме!

(Казан)




– Син сөт эчәсең,
Мин дә сөт эчәм.
Син дә үсәсең,
Мин дә дәү үсәм.

(Сарман, Мортыш-Тамак)



– Безнең дуслык – чын дуслык,
Безнең дуслык – бергәлек!
Җырлашабыз, көлешәбез –
Без уйныйбыз бергәләп.

(Казан)



– Уен яратам,
Эш тә сөямен:
Токмач кисәргә
Камыр җәямен.

(Мөслим,
Татар Буләр)

Балыкчылар

Иң батыр, иң матур мәче малае Мыр-Мырга өч яшь тулган көн иде.

Акбай, Шүрәле һәм Кәҗә белән Сарык бергә җыйналыштылар да «Мыр-Мырга ни бүләк итәргә икән?» дип бик озак уйлаштылар. Уйлый торгач, бер фикергә килделәр болар: балык тотып кайтырга булдылар.

Киттеләр бер мәлне тезелешеп: алдан Шүрәле, аның артыннан Акбай бара, алардан калышмаска тырышып, Кәҗә белән Сарык теркелди. Килеп җиттеләр болар бер кое янына, салдылар суга кармакларны. Берәм-берәм балык каптыра да башладылар. Шүрәле биш балык тотты, Акбай кармагына өч маймыч эләкте, Кәҗә бер балык каптырды. Сарык кына нәүмиз калды – ул сыңар балык та эләктерә алмады. Шулай да кәефләре шәп булды үзләренең: Мыр-Мырны сөендерерлек шактый балык тоттылар бит! Тотуын тоттылар, тик Сарык кына аптырашта калды: «Шүрәле, Акбай һәм Кәҗә барлыгы ничә балык тотты соң?»

Әйдәле, дускай, Сарыкка син дә булыш әле.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ.

(Җавап: Коеда балык тотмыйлар.)



Кызык-мызыклар




Рәсемнәрдәге аермаларны тап.


Кызык-мызыклар



Рәссам Максим ПОКАЛЕВ



Рәссамның үзеннән дә уздырып,
сурәтне буяп бетер.



Кәмитвәлигә кара да
аның баш киеменә охшаш башлык тап.

Сәлават күпере

4(134) — 2001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАТБУГАТ, ТЕЛЕРАДИОТАПШЫРУЛАР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ МАССАКҮЛӘМ КОММУНИКАЦИЯ ЧАРАЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ 1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства по делам печати, телерадиовещания и средств массовых коммуникаций РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Лилия ЗОЛОНДИНОВА рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кечә яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тәсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 13.4.2001 ел.
Басарга кул куелды 13.4.2001 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басылд.
Тиражы 16320 данә. Заказ А-146.
Бәясе килешү буенча.



Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Габдулла Тукай

Кызыклы шәкерт

– Әйдәле, Акбай, өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума, туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

– Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга ике айлап булыр, я өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә.
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

– Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул,
Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!

